| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**14.02.2017** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 168** |

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2016 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре турында һәм 2017 елга бурычлар хисабы турында

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы А. В. Тыгинның 2016 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2017 елга бурычлар турында хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары» турында Федераль законның 35, 36 статьяларына, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2016 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2017 елга бурычлар турында хисабын игътибарга алырга.
2. 2016 елда Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының эшен канәгатьләнерлек дип танырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты:

3.1. Зеленодольск муниципаль районы Советына 2016 елда үз эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2017 елга бурычлар турында Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы хисабында күрсәтелгән барлык юнәлешләр буенча тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар планын эшләргә һәм 2017 елның 20 мартына кадәр тапшырырга;

3.2. Әлеге карарның 3.1 пунктчасы нигезендә, планга кертелгән чараларның үтәлеше турында квартал саен Зеленодольск муниципаль районы Советына хәбәр итәргә;

3.3. 2017 елның 15 декабренә кадәр Зеленодольск муниципаль районы Советы сессиясендә карау өчен чаралар планының үтәлеше турында йомгаклау мәгълүматын кертергә.

4. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2016 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2017 елга бурычлар турында хисабын «Зеленодольская правда» һәм «Яшел Үзән» газеталарында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

(http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы башлыгы урынбасары Ф.Н. Шәмсиевка йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**